# Гадәти, әмма гыйбрәтле тормыш юлы...



Булачак шагыйрь Муса Мостафа улы Җәлилов 1906 елның 15 февралендә (иске стиль белән 2 февралендә) Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында дөньяга килә. Алты яшеннән авыл мәктәбендә, аннан соң 1914—1917 елларда Оренбургтагы атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Беренче шигырен Муса 9 яшендә яза. Шул чорда ук алдынгы, «сул» фикерле укучылардан саналган Муса иҗатка тартыла, әдәбият белән кызыксына, кулъязма журналда тәүге шигырьләрен дә урнаштырып карый…



# Җырларым...



- Шагыйрьнең иң танылган әсәре – «Җырларым» (1943) шигыре М. Җәлилнең васыяте, тормыш-яшәеш, бәхилләшү программасы дисәк тә ялгыш булмас. Аның киеренке кичереше, җырларына баглаган өмете укучыны битараф калдыра алмый. “Җырларым” шигырендә җыр символик образы берничә мәгънә төсмере белән алына: бердән, шагыйрьнен әсәрләре билгесе булып килә :

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз..!

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигъремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

# Муса Җәлил - Совет герое.

- Бөек Ватан сугышында күрсәткән ныклыгы һәм батырлыгы өчен, СССР Верховный советы белән, үлүеннән соң, шагыйрь Муса Җәлилгә 1956 елның 2 нче февралендә Советлар Союзы герое исеме бирелде.
- Фашизм тоткынлыгында иҗат ителгән һәм укучыларга “Моабит дәфтәрләре” исеме белән билгеле булган шигырьләр җыентыгы өчен М. Җәлил 1957 елның 22 апрелендә Ленин премиясенә лаек булды.